РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.04.2019

КАРАР
№ 26

Юлбат авыл башкарма комитетының 2017 елның 15 мартында 9 нчы номер белән расланган “Юлбат авыл башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 2019 елның 3 нче апрелендәге 02-08-02-63-2019 нчы номерлы протесты нигезендә, Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Юлбат авыл башкарма комитетының 2017 елның 15 мартында 9 нчы номер белән расланган “Юлбат авыл башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында” карарының 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктча белән тулыландырырга:

- Гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документлар яки мәгълүматларның юклыгы яки төгәлсезлеге беренче тапкыр документларны кабул иткәндә күрсәтелмәгәндә, яисә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пункты белән каралган очраклардан тыш, документлар яки мәгълүматлар таләп итү. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судсыз) күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләрен(гамәл кылмавын) шикаять итү, мөмкин шул очракта, әгәр карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителүче күпфункцияле үзәккә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса.

2. 5.8 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

Шикаятьне карау яки караганнан соң барлыкка килгән нәтиҗәләр буенча административ хокук бозу яки җинаять очрагы расланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле хезмәткәр яки вазыйфаи зат “Дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 11.2 статьясы 1 бүлегенә туры китереп, булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/ulbat, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р.Шәмсиев